**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел.+7(84396) 4-35-10 тел./факс +7(84396) 4-35-09, email: Ispolkom.Cheremshan@tatar.ru; http://cheremshan.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.11.2025 ел **Чирмешән авылы** № 361

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданнар милкенә (арендага) индивидуаль торак төзелеше өчен бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 17 декабрендәге 524 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Җир кодексына һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 34 статьясындагы 7 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында» Федераль законның 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 28 декабрендәге 538-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль милектәге җир кишәрлеген гражданнар милкенә (арендага) индивидуаль торак төзелеше өчен бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 17 декабрендәге 524 номерлы карарына (2021 елның 23 июнендәге 253 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.8 нче пунктның 13 нче пунктчасында:

- «бастырып чыгарылды һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;
- «бакчачылык» сүзен «гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып баруы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе                                                                                    И.М.Җамалетдинов